Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шомбыт авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 16**

Шомбыт авылы 2017 елның 27 сентябре

Шомбыт авыл җирлеге башлыгының акчалата бүләкләү күләмен һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладларын индексацияләү турында

«Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең акчалата түләүләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазыйфаи эш хаклары күләмнәрен индексацияләү турында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 28 июлендәге 525 номерлы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Шомбыт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2017 елның 1 октябреннән 1,049 тапкыр арттырырга (индексацияләргә):

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге Советының 2016 елның 8 сентябрендәге 15 номерлы “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары турында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфалар биләүче затларга муниципаль вазыйфадан пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибе турында”гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге Башлыгының акчалата бүләкләүне;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге Советының 2016 елның 06 октябрендәге 18 номерлы “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге

муниципаль хезмәткәрләренең айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында" гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладларын;

2. Билгеләргә:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән хезмәткәрләрнең акчалата бүләкләү һәм вазыйфаи окладлары күләмен, шулай ук айлык өстәмәләр һәм түләүләр күләме күтәрелгәндә (индексациялəгәндә) бер сумга кадәр артырга тиеш

әлеге карарның 1 пунктын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау җирле бюджетта тиешле финанс елына каралган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырыла.3.Копию настоящего решения направить в Финансово-бюджетную палату Рыбно-Слободского муниципального района Республики Татарстан.

**4.** Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлегенең Шомбыт авылы, Совет урамы, 18 йорт; Шомбыт авылы, Завод урамы, 22 йорт; Шестая Речка авылы, Лесная урамы, 6 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шомбыт авыл җирлеге Башлыгы Н.Е.Сергеев